**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 ел **Чирмешән авылы** № 363

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 454 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнар милкенә (арендага) муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 ноябрендәге 454 номерлы карарына (2020 елның 16 сентябрендәге № 321, 2025 елның 12 мартындагы № 64 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8 пунктында:

- 13 пунктчада «бастырылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

- 16 пунктчада «чик» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов